**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ**

2026 елның 16 гыйнвары №14

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 17 тапрелендәге 73 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карарларын ,"Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы карарын үтәү йөзеннән , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы «муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 17 тапрелендәге 73 номерлы карарына (2018 елның 31 маендагы № 75, 2018 елның 15 ноябрендәге № 96, 2019 елның 3 июнендәге № 116, 2020 елның 6 октябрендәге № 10, 2022 елның 27 сентябрендәге № 62, 2022 елның 20 октябрендәге № 64, 2022 елның 23 декабрендәге № 73, 2024 елның 27 июнендәге № 113, 2024 елның 12 декабрендәге № 125, 2025 елның 15 маендагы № 141 карарлар редакциясендә)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә":

2 статьяның 1 пунктындагы 1 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) | |
|---|---|---|
| | 11 төркем (халык саны 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр ) | 12 төркем (халык саны 1,5 меңгә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 25 401 | 23 201 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 18 254 | 16 931 |

»;

2 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

" 1)вазыйфаи оклад, муниципаль хезмәтнең билгән муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеменең вазыйфаи окладына тапкырланып ,16 928 сум күләмендә билгеләнә»

4 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"3. Бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре Кама Тамагы районы бюджет өлкәсендә хезмәткәрләрнең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи оклады күләменә тапкырлап исәпләнә, ул 16 928 сум тәшкил итә."

4 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифасы | Түбәндәге халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 31 000 | 32 700 |
| Бухгалтер, икътисадчы | 28 300 | 29 700 |

».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан көченә керә һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырыла.

3. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тоту "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге башлыгына йөкләнә.

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы  Куйбышев Затоны
шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль
берәмлеге башлыгы, Кама Тамагы
муниципаль районы  Куйбышев Затоны
шәһәр тибындагы поселогы "
муниципаль берәмлеге Советы рәисе Н.Б. Ефимов